ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2021 ел, 14 апрель № 31

Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2008 елның 25 нче декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. «Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының 2017 елның 7 августындагы Сатмыш авыл җирлеге Советының 75 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлеге депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль вазыйфаны биләүче зат (авыл җирлеге Советы депутатларының муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы затлардан тыш) ел саен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта түбәндәгеләрне тапшыра:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрьдә);

2) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында белешмәләр, шулай ук аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрь);

3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыймметле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорына цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда шушы затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.

Авыл җирлеге депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат депутат булып сайланган көннән алып дүрт ай эчендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләр үтәүне туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры) тапшыру елыннан алдагы һәр ел эчендә, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар

чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында".Хисап чоры дәвамында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 19 июлендәге 2 статьясындагы 2 өлешендә каралган махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып хәбәр итү юнәлеше аша хәбәр итә.
Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында" 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, күрсәтелгән Законга кушымта нигезендә формада. Хәбәрнамә, шулай ук белешмәләр (дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында) 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта бирелә.

Авыл җирлеге Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы зат тарафыннан имзаланган кәгазь чыганактагы хәбәрнамәнең күчермәсе тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:

«2.2.Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес һәм тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчыга кадәр, җирлек Советында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү.;

4) үз вәкаләтләре чоры туктатылганчы җирлек Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек Башлыгына йөкләргә.

Сатмыш авыл
җирлеге Башлыгы Р.Р. Сибгатова